ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.03.2021 Баулы шәһәре №23

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының карары белән расланган кайбер административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 13 маендагы 205 номерлы карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

1.5. пунктта беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә органнары бирә торган белешмә (өземтә) дигәндә хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт китабыннан архив өземтә, алдагы яшәү урыныннан белешмә, көнкүреш характеристикасы күздә тотыла»;

2нче «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүләрне алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне таныклый торган документ;

2) муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап, мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, аның вәкаләтләрен таныклаучы документ (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);

3) гариза:

- кәгазь чыганактагы документ формасында (1нче кушымта);

- республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (интерактив формага тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла); «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк булган очракта һәм әгәр федераль закон

нигезендә мондый шәхси белешмәләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә күрсәтелгән затның яисә аның вәкиленең шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә законлы ризалыгын алуны раслый торган документларны тапшыра. Килешү алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче башкарма комитетта шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

- шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);

- почта аша җибәреп.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталы аша электрон документлар формасында тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.»;

1нче кушымтаны кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә;

2нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

2. Агач кисү яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.6. пунктына түбәндәге эчтәлекле 2нче пунктча өстәргә:

«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш);

2.8. пунктына түбәндәге эчтәлекле 5нче пунктча өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

3. Контроль за исполнением настоящего постановления оставляю за собой.

3нче бүлегендә: «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре»

3.4.1. пунктында «күчемсез милек объектына» сүзләреннән соң «, һәм салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы (барлыгы) турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

“Баулы шәһәре” муниципаль

берәмлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Белешмә (өземтә) бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
1нче кушымта

______________________________
(кайда - муниципаль берәмлекнең
җирле үзидарә органы исеме)

______________________________
(кемнән – мөрәҗәгать итүче).

______________________________

______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме,
паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны
буенча теркәлү, телефон)

Белешмә (өземтә) алу турында гариза

Түбәндәге белешмәне (өземтәне) бирүегезне үтенәм

___________________________________________________________________________

(белешмә төрен күрсәтергә)
Түбәндәге адрес буенча:___________________________________________________________

Гаризага түбәндәге документларны терким:
1. ____________________________________________________________________
2. ____________________________________________________________________
3. ____________________________________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйм

_______________________________________________

____________________/________________________/_____________________________

(дата) (имза) (Ф.И.О.)